**СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Мульма, ул. Центральная, 46а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мүлмә авылы., Үзәк ур., 46а

Тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail:Mulm.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18 июль, 2022 ел** **№ 52**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 124 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 10.08.2020 №211, 19.01.2021 №18 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мүлмә авыл җирлеге Советының 2021 елның 38 номерлы ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Мүлмә авыл җирлеге Советының 2021 елның 38 номерлы ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 25 нче октябрендә 10.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Мүлмә авылы, Үзәк урамы, 38а йортында үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 188 номерлы карары белән кабул ителгән ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге»

муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 10.08.2020 №211, 19.01.2021 №18 карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Л.Р. Зиннәтуллин